БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12 ноябрь 2020 ел № 22

**Балтач район Советының 2011 елның 28 октябрендәге 64 номерлы "Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләнгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында"гы карарның үз көчен югалтуын тану хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 26 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 29 июнендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның (2016 елның 2 июнендәге редакциядә) 5 статьясындагы 8 пункты, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Балтач район Советының 2011 елның 28 октябрендәге 64 номерлы "Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен йөкләнгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында"гы карарны (2012 елның 29 августындагы 125 номерлы редакциясендә) 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карар Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматыныц рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р. Нотфуллин